## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Хуҗа Хәсән авыл җирлегенең Хуҗа Хәсән торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**30 ноябрь 2024 ел** **№ 8**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 29 ноябрендә 11 сәгатьтә, 2024 елның 29 ноябрендә 16 сәгатьтә, 2024 елның 30 ноябрендә 12 сәгать 00 минутта, 2024 елның 30 ноябрендә 14 сәгать 30 минутта, этаплап булган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән «Сез 2025 елда яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Хуҗа Хәсән авыл җирлегенең Хуҗа Хәсән торак пунктында теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме соравы буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

-урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;

-су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю биналарын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү;

-торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

-каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү.

- материаллар сатып алып, зиратларны чистарту һәм ремонтлау.

Экономия барлыкка килгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлеге Башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен акча җибәрергә рөхсәт итәргә.»

« РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 389 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны -205, бу 52,7 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен гражданнар җыенында 205 катнашучы тавыш бирде;

"Юк" позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Хуҗа Хәсән авыл җирлегенең Хуҗа Хәсән торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. «Сез 2025 елда яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Хуҗа Хәсән авыл җирлегенең Хуҗа Хәсән торак пунктында теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме соравы буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде :

-урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;

-су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю биналарын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү;

-торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

-каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү.

Экономия барлыкка килгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлеге Башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен акча җибәрергә рөхсәт итәргә.» соравы буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Хужа Хәсән авыл жирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен жибәрергә.

Гражданнар жыенында рәислек иткән,
Хужа Хәсән авыл жирлеге Башлыгы С.П.Матвеева